МИНИСТЕРСТВО ТРАНСПОРТА
И ДОРОЖНОГО ХОЗЯЙСТВА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТРАНСПОРТ ҺӘМ ЮЛ
ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

**БОЕРЫК** **ПРИКАЗ**

**от “ 19 ” ноября 2018** **№ 578**

Казан шәһәре

Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының 2016 елның 11 апрелендәге 74 номерлы “Татарстан Республикасы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутлары реестрын алып бару тәртибен раслау турында” боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутлары реестрын алып бару тәртибенә үзгәреш кертү турында

Закончылыкка туры китерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

1. Яңа редакциядә бәян итеп (кушымта итеп бирелә), Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының 2016 елның 11 апрелендәге 74 номерлы “Татарстан Республикасы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутлары реестрын алып бару тәртибен раслау турында” боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутлары реестрын алып бару тәртибенә үзгәреш кертергә.
2. Транспорт идарәсенең автомобиль транспорты булеге мөдире Н.Н. Доброхотовка әлеге боерыкка Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәве уздырырга.

Министр Л.Р. Сафин

Татарстан Республикасы
транспорт һәм юл
хуҗалыгы министрлыгының
2016 елның 26 февралендәге
74 номерлы боерыгы белән расланды
(Татарстан Республикасы транспорт
һәм юл хуҗалыгы министрлыгының
2018 елның 19 ноябрьдәге 578 нче
номерлы боерыгы редакциясендә)

Татарстан Республикасы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутлары реестрын алып бару тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутлары реестрын (алга таба – Реестр) алып бару тәртибе даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутлары (алга таба - муниципальара маршрутлар) турында белешмәләр кертү кагыйдәләрен, муниципальара маршрутлар турында үзгәрешләр кертүне, муниципальара маршрутлар турында белешмәләрне Реестрдан чыгаруны билгели.

2. Реестр муниципальара маршрутларның бердәм информацион мәглүматлар базасы булып тора.

3. Фактта барлык гамәлдә булган яки Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы (алга таба – Министрлык) белән гамәлдән чыгарылган муниципальара маршрутлар турында белешмәләр реестрга кертелергә, үзгәрергә яки реестрдан чыгарылырга тиеш булып тора.

4. Реестр электрон формада алып барыла һәм Министрлыкның “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

5. Реестрны алып бару Реестрга тиешле үзгәрешләр кертү юлы белән гамәлгә ашырыла. Реестрга үзгәрешләр яңа муниципальара маршрутлар билгеләгәү сәбәпле, булган муниципальара маршрутларны үзгәртү яки туктату сәбәпле кертелә.

6. Реестрга түбәндәге белешмәләр кертеләләр:

- муниципальара маршрутларның теркәү номеры;
- муниципальара маршрутларның тәртип номеры;
- даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның маршруты атамасы муниципальара маршрут буенча башлангыч туктау пункты һәм соңгы туктау пункты атамалары рәвешендә яки чикләрендә бу муниципальара маршрут буенча башлангыч туктау пункты һәм соңгы туктау пункты урнашкан авыл җирлекләре яки шәһәр округлары атамалары рәвешендә;
- муниципальара маршрут буенча арадаш туктау пунктларының атамалары яки чикләрендә арадаш туктау пунктлары урнашкан авыл җирлекләре яки шәһәр округлары атамалары;
- муниципальара маршрут буенча туктау пунктлары арасында транспорт чаралары хәрәкәте каралган урамнар, автомобиль юллары атамалары;

- муниципальара маршрут озынлыгы;

- пассажирлар утырту һәм төшерү тәртибе (фәкать, билгеләнгән туктау пунктларында гына яки, әгәр федераль закон белән тыелмаса, муниципальара маршрут буенча юл хәрәкәте кагыйдәләре белән тыелмаган теләсә кайсы урында);

- даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның төре;

- муниципальара маршрут билгеләү яки дәүләт контракты һәм (яки) муниципальара маршрут буенча даими пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклык бирелгән ачык конкурста катнашучы тарафыннан ачык конкурста катнашуга җибәрелгән гариза белән үзгәрү турында карар белән каралган транспорт чараларының характеристикалары (транспорт чараларының төре, транспорт чараларының классы, транспорт чараларының экологик характеристикалары, транспорт чараларының эксплуатацияләүнең максималь вакыты, пассажирлар йөртү сыйфатына йогынты ясый торган транспорт чараларының характеристикалары);

- муниципальара маршрут буенча пассажирлар йөртү өчен файдаланырга рөхсәт ителә торган, һәр класс транспорт чараларының максималь саны;

- даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыра башлау датасы;

- муниципальара маршрут буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашырган юридик затның атамасы, табылу урыны, индивидуаль эшмәкәрнең (шулай ук гади ширкәт шартнамәсе катнашучыларының) фамилиясе, исеме һәм, әгәр булса, атасының исеме, салым түләүченең идентификация номеры.

7. Билгеләнгән яки үзгәртелгән муниципальара маршрут турында белешмәләр Реестрга Министрлыкның тиешле карары кабул ителгән көннән, эш көннәрендә исәпләнгән 5 көнле срок эчендә, кертелә.

Туктатылган муниципальара маршрут турында белешмәләр Реестрдан Министрлыкның тиешле карары кабул ителгән көннән, эш көннәрендә исәпләнгән 5 көнле срок эчендә, чыгарыла.

Маршрут таныклыгы һәм картасы бирелгән юридик зат, индивидуаль эшмәкәр, гади ширкәт шартнамәсендә катнашучы турында белешмәләр маршрут таныклыгын һәм картасын бирү көненнән соң килүче көннән дә соңга калмыйча Реестрга кертелә.

8. Реестрны алып бару Министрлыкның Транспорт идарәсенең автомобиль транспорты булеге (алга таба – бүлек) белән гамәлгә ашырыла.

9. Бүлек белешмәләрне Реестрга үз вакытында һәм дөрес итеп кертү өчен җаваплы.

10. Министрлыкның мәгълүматлаштыру һәм мәгълүмат секторы Реестрны Министрлыкның “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге (алга таба – “Интернет” челтәре) рәсми сайтында урнаштырыну гамәлгә ашыра.

Реестрга тиешле үзгәрешләр керткән көннән ул “Интернет” челтәрендә бер эш көне дәвамында яңартылырга тиеш.

11. Реестрга кертелгән һәм “Интернет” челтәрендә урнаштырылган белешмәләр танышу өчен түләүсез файдаланыла.